РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕВЛАШТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422075,Республика Татарстан, Сабинский район, с.Евлаштау, ул. Ш.Бариева, д.23
тел. (84362) 46-8-49

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯВЛАШТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422075, Татарстан Республикасы, Саба районы, Явлаштау авылы, Ш.Бариев урамы, 23 йорт
тел. (84362) 46-8-49

e-mail: Evlash.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
02.06.2021

КАРАР
№21

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 нче елның 14 нче мартында кабул ителгән 6нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруның административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 30.12.2020 ел, № 509-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге башкарма комитеты

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге чикләрендә «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 нче елның 14 нче мартында кабул ителгән 6 нчы номерлы карары белән расланган административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   1.1. 5 пунктта «электрон формада» сүзләрен «электрон формада, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенә карата да, аларны алу өчен алар мөрәҗәгать иткән» сүзләренә алмаштырырга.
2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба

муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/ evlashtay адресы буенча, җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Нуриев